| МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

09.10.2017 № 712

г.Казань

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2017 елның 24 октябрендә теркәлде, № 4150

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2011 елның 10 маендагы 244 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру методикасына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Президентының "Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә конкурс турында" 2005 елның 1 февралендәге 112 номерлы Указы нигезендә боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының "Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру методикасын раслау турында" 2011 елның 10 маендагы 244 номерлы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 26.07.2013 № 455 һәм 12.05.2014 № 254 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру методикасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктында "граждан хезмәте вазыйфасына карата" сүзләрен "граждан хезмәте вазыйфасын биләү өчен" сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктның икенче абзацында:

"Интернет" мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә" сүзләреннән соң "Интернет" (алга таба – "Интернет" челтәре) сүзләрен өстәргә;

"бу вазыйфаны биләүгә дәгъва белдерүчегә куела торган таләпләр" сүзләрен "бу вазыйфаны биләү буенча квалификация таләпләре" сүзләренә алмаштырырга;

6 пунктының "б" пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"б) Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган рәвештәге, тутырылган һәм имзаланган анкетаны, фотосы белән";"

7 пунктында:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Бүтән дәүләт органында уздырыла торган конкурста катнашу теләген белдергән граждан хезмәткәре шушы дәүләт органына эшкә алучы вәкиле исеменә тутырылган, имзаланган һәм үзе граждан хезмәте вазыйфасын били торган дәүләт органының кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган рәвештәге анкетаны фотосын теркәп тапшыра.";

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

"Шушы Методиканың 6 һәм 7 пунктларында күрсәтелгән документлар "Интернет" челтәрендә дәүләт хезмәте өлкәсендәге дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында аларны кабул итү турында игълан урнаштырылган көннән башлап 21 календарь көне эчендә Министрлыкка гражданин (граждан хезмәткәре) тарафыннан шәхсән, почта аша җибәреп яисә, күрсәтелгән мәгълүмат системасыннан файдаланып, электрон рәвештә җибәрелә.

Документларны электрон рәвештә тапшыру тәртибе Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.

Хөрмәткә лаек сәбәпсез документларны үз вакытында тапшырмау, аларны тулы күләмдә тапшырмау яисә рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшыру гражданиннан (граждан хезмәткәреннән) аларны кабул итүдән баш тартуга нигез булып тора.

Хөрмәткә лаек сәбәп аркасында документларны үз вакытында тапшырмаганда, аларны тулы булмаган күләмдә яисә рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшырганда, эшкә алучының вәкиле аларны карап тикшерүнең вакытын күчерергә хокуклы.";

8 пунктында "граждан хезмәте вазыйфасына карата" сүзләрен "граждан хезмәте вазыйфасын биләү өчен" сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле яңа $9^1$ пунктын өстәргә:

"$9^1$. Гражданин тарафыннан Министрлыкка тапшырылган белешмәләрнең дөреслеге тикшерелергә тиеш. Электрон рәвештә тапшырылган белешмәләр Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә автоматлаштырылган рәвештә тикшерүгә дучар була.

Граждан хезмәткәре тарафыннан тапшырылган белешмәләрнең дөреслеген тикшерү бары тик ул граждан хезмәтенең иң югары вазыйфалар төркеменә караучы граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләү буенча конкурста катнашкан очракта гына гамәлгә ашырыла.";

10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"10. Конкурсның икенче этабын уздыру датасы, урыны һәм вакыты турында карар граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә дәгъва белдерүчеләр тарафыннан

тапшырылган белешмәләрнең дөреслеге тикшерелгәннән соң, шулай ук, зарурлык булу очрагында, дәүләт серен һәм закон белән саклана торган бүтән серне тәшкил итүче белешмәләрдән файдалануга рөхсәт рәсмиләштерелгәннән соң, Министр тарафыннан кабул ителә. Конкурсның икенче этабы конкурста катнашу өчен документларны кабул итү тәмамланган көннән соңгы 30 календарь көненнән дә соңга калмыйча уздырыла, ә дәүләт серен һәм закон белән саклана торган бүтән серне тәшкил итүче белешмәләрдән файдалануга рөхсәт рәсмиләштерелгән очракта конкурсның икенче этабын уздыру вакыты Министр тарафыннан билгеләнә.

Тикшерү барышында гражданинның Федераль законнар һәм Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актлары нигезендә граждан хезмәтенә керүенә комачау итүче шартлар ачыкланган очракта, аңа конкурста катнаштырудан кире кагуның сәбәпләре турында Министр тарафыннан язмача рәвештә хәбәр ителә. Әгәр гражданин конкурста катнашу өчен документларны электрон рәвештә тапшырган булса, конкурста катнаштырудан кире кагу сәбәпләре хакында хәбәрләмә аңа, дәүләт хезмәте өлкәсендәге дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрелә.";

12 пунктының беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"12. Министрлык үзенең рәсми сайтында һәм "Интернет" челтәрендә дәүләт хезмәте өлкәсендәге дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында конкурсның икенче этабы башланырга 15 календарь көненнән соңга калмыйча аны уздыру датасы, урыны һәм вакыты турында мәгълүмат, конкурста катнашуга кертелгән гражданнар (граждан хезмәткәрләре) (алга таба – кандидатлар) исемлеген урнаштыра һәм кандидатларга тиешле хәбәрләрне язмача рәвештә җибәрә, бу вакытта конкурста катнашу буенча документларны электрон рәвештә тапшырган кандидатларга, – күрсәтелгән мәгълүмат системасыннан файдаланып, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә.";

13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"13. Әгәр конкурсны уздыру нәтиҗәсендә граждан хезмәтенең вакант вазыйфасын биләү өчен квалификация таләпләренә җавап бирүче кандидатлар ачыкланмаса, Министр конкурсны яңадан уздыру турында карар кабул итәргә хокуклы.";

20 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"20. Конкурс нәтиҗәләре хакында хәбәрләр ул тәмамланганнан соң 7 көнлек чорда кандидатларга язмача рәвештә, бу вакытта конкурста катнашу өчен документларны электрон рәвештә тапшырган кандидатларга дәүләт хезмәте өлкәсендәге дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрелә. Шушы ук чорда конкурс нәтиҗәләре турындагы мәгълүмат Министрлыкның рәсми сайтында һәм "Интернет" челтәренең күрсәтелгән мәгълүмат системасында да урнаштырыла".";

21 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"21. Граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә дәгъва белдергән, ләкин конкурста катнашуга кертелмәгән кандидатларның һәм конкурста катнашкан кандидатларның документлары язмача гаризалары буенча конкурс тәмамланган көннән соң өч ел дәвамында аларга кайтарып бирелергә мөмкин. Әлеге чор тәмамланганчыга кадәр документлар Министрлык архивында саклана, аннан соң юкка чыгарылырга тиеш. Конкурста катнашу өчен электрон рәвештә тапшырылган документлар өч ел саклана, шуннан соң юкка чыгарылырга тиеш.".

Министр Э.Ә. Зарипова